КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 15 апрель г.Казань № 411

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 20 май, 479 нчы карары белән расланган Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарын ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм туклануга бәйле чыгымнарын каплау өчен оешмаларга һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны

урнаштыруга һәм туклануга бәйле чыгымнарын каплау өчен оешмаларга һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 май, 479 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 25 август, 896 нчы; 2023 ел, 21 гыйнвар, 29 нчы; 2023 ел, 23 февраль, 179 нчы; 2023 ел, 14 август, 974 нче; 2024 ел, 7 май, 312 нче; 2024 ел, 29 октябрь, 935 нче; 2024 ел, 16 декабрь, 1146 нчы; 2025 ел, 25 июнь, 457 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Украина территориясендә, шулай ук максималь һәм уртача дәрәҗәдә чара күрү кертелгән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм туклануга бәйле чыгымнарын каплау өчен оешмаларга һәм инвидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

3.7 пунктта «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.1 пунктның беренче абзацында татар текстында «Субсидия» сүзен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин